**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ СӘФӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423748, Иске Сэфэр авылы,
М.Вахитов ур., 16 нчы йорт.
Тел.5-60-43

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА СОВЕТА
СТАРОСАФАРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423748, село Старое Сафарово,
ул. М.Вахитова ,дом 16 , Тел. 5-60-43

КАРАР
«05» ноября 2019 ел

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ 2

Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлегенең Иске Сәфәр торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Иске Сәфәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Иске Сәфәр авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 20 нояберенә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Иске Сәфәр, Иске Кадырмәт, Терпельдә урам юлларын ремонтлау һәм карап тоту (ПГС һәм вак таш салу, грейдлау, кардан чистарту);
- Иске Сәфәр авылында Терпеле елгасы аша җәяүлеләр күперен ремонтлау
Җирлек чикләрендә Халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:
- Иске Сәфәр, Иске Кадырмәт, Терпеледә скважиналарны лицензияләү, су челтәрләрен карап тоту һәм алыштыру;;
Авыл җирлегендә яшәүчеләрнең массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру
- Иске Кадырмәт һәм Терпеле авылларындагы һәйкәлне ремонтлау һәм реконструкцияләү ; ;
Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
-- зират коймасын ремонтлау; зират коймаларын буяу өчен лак-буяу материаллары сатып алу;
- җирлек территориясендә агач кисү;
Җирлек территориясендә төзекләндерү эшләрен оештыру:

- җирлек территориясендәге хуҗасыз объектларны һәм йортларны сүтү;
- урамнарны яктырту электр челтәрләрен урнаштыру, тоту;
- торак пунктларда урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру;

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Иске Сәфә авылы, М.Вахитов урамы, 16 нчы йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Иске Сәфәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Сайфор Г.З.Сайфутдинова